**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**28.10.2016** **№ 1202 - п**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурс үткәрү турында Нигезләмәне раслау турында

2004 елның 27 июлендәге №79-ФЗ "Россия Федерациясендә гражданлык хезмәте турында" Федераль Законга, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында" Указы, 2003 елның 16 январендагы №3-ЗРТ "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге вакантлы вазыйфаларны биләүгә кандидатларны сыйфатлы сайлап алу һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында нәтиҗәле кадрлар резервы формалаштыру максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурс үткәрү турында кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Министрлыкның 2014 елның 12 маендагы №345-п "Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында" боерыгын гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Документларның үтәлүен тикшерү бүлегенә (Г.Р.Ханнанова) бу боерыкны Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә җиткерергә.

5. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К.Сәлимгәрәев) бу боерыкны, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвеннән соң, Министрлыкның "Татарстан Республикасы рәсми порталы" дәүләт мәгълүмат системасы составындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И.Камаловка йөкләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.И.Камалов

Татарстан Республикасы Экология һәм
табигый байлыклар министрлыгының
28.10.2016 №1202-п боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында

**Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу нигезләмә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба –конкурс) үткәрү тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә (алга таба - гражданлык хезмәте) тигез мөмкинлеккә конституцион хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында (алга таба – Министрлык) конкурс 2004 елның 27 июлендәге №79-ФЗ “Россия Федерациясендә гражданлык хезмәте турында” Федераль Законның 22нче маддәсе, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында” Указы, 2003 елның 16 январендагы №3-ЗРТ “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы №УП-127 “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау турында” указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфага булган квалификацион таләпләргә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Министрлыкның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булган структур бүлекчәсе җитәкчесенең Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге белән килешенгән нигезле язмача мөрәҗәгате (бу Нигезләмәгә Кушымта №1) нигезендә Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан Министрлыкның белгечләргә ихтимал булган ихтыяҗына һәм Министрлыкның булган кадрлар резервына һәр елны үткәрелә торган бәяләү нәтиҗәләре буенча уздырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан бу Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

1.4. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелми:

гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләре буенча вәкаләтләре билгеле бер срок дәвамында биләнә торган эшкә билгеләгәндә;

гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” категориясенә эшкә билгеләү һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган вазыйфаларга эшкә билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

2004 елның 27 июлендәге 79 номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” Федераль законның 28 маддәсенең 2 өлеше, 31 маддәсенең 1 өлеше, 60.1 маддәсенең 9 өлешендә каралган очракларда гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең бүтән вазыйфасына эшкә билгеләгәндә;

гражданлык хезмәте вазыйфасына гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданны) эшкә билгеләгәндә.

1.5. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

гражданлык хезмәтенең вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү дәүләт сере булып торган мәгълүматлар куллану белән бәйле булган аерым вазыйфаларына эшкә билгеләгәндә, Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча;

гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган гражданлык хезмәте вазыйфасына эшкә билгеләгәндә, министр карары буенча.

1.6. Конкурс үткәрү максатлары:

сәләтләре һәм профессиональ әзерлекләренә туры китереп, Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт гражданлык хезмәтенә тигез мөмкинлеккә конституцион хокуын, шулай ук гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән барлык кандидатлар арасыннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә аеруча яраклы кандидатларны сайлап алу;

гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә, барлык кандидатлар өчен тигез шартлар булдыру;

кандидатларны гражданлык хезмәте культурасына, профессиональ компетентлык һәм шәхси-эшлекле сыйфатлар критерийлары нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервы гражданлык хезмәте вазыйфасы) таләпләренә туры килә торган затларны конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән билгеләү.

## II. **Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эш тәртибе**

2.1. Министрлыкта Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” Указы нигезендә составы Министрлык боерыгы белән раслана торган даими гамәлдәге комиссия оештырыла. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргән очракта, министрлык боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан башкарыла. Конкурс комиссиясе рәисе булмаган чакта, аның хокук һәм бурычларын комиссия рәисе урынбасары үти.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итү, теркәү, делолар формалаштыру, конкурста катнашучылар исәбе журналын алып бару, конкурс комиссиясе карарларын теркәп бару һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары һәм (яки) министр тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән, хокукый тәэмин итү бүлегеннән, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәдән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле, шулай ук Министрлык соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар сыйфатында чакырыла торган – гражданлык хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр – фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә, экспертларның персональ мәгълүматлары күрсәтелми.

Конкурс комиссиясенә кертү өчен Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатураларын министр соравы буенча әлеге комиссия тәкъдим итә.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының чирегеннән ким булмаска тиеш.

2.5. Вазыйфаи йөкләмәләрен үтәү дәүләт сере булган мәгълүматларны файдалану белән бәйле булган дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу мөмкинлегенә юл куймаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервындагы дәүләт хезмәте вазыйфасына) икедән ким булмаган кандидат булганда үткәрелә һәм анда әгъзаларының гомуми санының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы санала. Конкурс комиссиясе утырышын гражданлык хезмәте вазыйфаларын били торган әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

Конкурс үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле методик һәм башка материалларны раслый;

дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъвалый торган гражданнарга (гражданлык хезмәткәрләренә) конкурсны үткәрү шартлары турында мәгълүмат һәм консультация бирә;

кандидатлар соратуы буенча, конкурс документларын бирә;

дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатлар тарафыннан тәкъдим ителгән документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурс йомгакларын ясау турында, кандидатны конкурсның җиңүчесе итеп тану турында карар кабул итә, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен рекомендация бирә.

2.9. Конкурс комиссиясенең конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча карары, ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавыш биргәндә, конкурс комиссиясе әгъзаларының фикере “өчен” яки “каршы” сүзләре белән белдерелә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисененең тавышы хәлиткеч булып тора. Конкурсның һәр әгъзасы, кабул ителгән карар белән килешмәгәндә, аерым фикерен белдерә ала, бу фикер конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы имзасы белән ныгытыла.

2.10. Конкурс комиссиясенең карары кандидат юк чакта кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү (аның ризалыгы белән кадрлар резервына кертү) өчен яки моны кире кагу өчен нигез булып тора.

2.11. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары кул куя. Гражданлык хезмәте вазыйфасына беренче тапкыр билгеләнә торган гражданга яки гражданлык хезмәткәрен Министрлыктагы башка төркем яки категория гражданлык хезмәте вазыйфасына күчергәндә, сынау срогының дәвамлылыгы турында конкурс комиссиясе тарафыннан рекомендация бирелергә мөмкин.

2.12. Конкурсны оештыру һәм үткәрелешен тәэмин итүне, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашу Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга таләпләргә туры килә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында күрсәтелгән срокларда тапшырган гражданнарга рөхсәт ителә.

3.2. Конкурска гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасына) квалификация таләпләренә туры килмәү сәбәпле, шулай ук гражданлык хезмәтенә

керү һәм аны үтү өчен Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнары чикләүләре белән бәйле рәвештә кертелми.

3.3. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга таләпләр (әлеге Нигезләмәгә Кушымта №3) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары нигезендә билгеләнде.

3.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Министрлыкка тапшыра:

а) шәхси гариза (әлеге Нигезләмәгә Кушымта № 2);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы  № 667-р әмере белән расланган формадагы анкетаны үз кулы белән тутырып һәм имзалап, фотографиясен беркетеп (4 х 6 см, почмаксыз);

в) паспорт яки аны алыштыра торган документ копиясен (конкурска килгәч, документ үзе шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм стажны раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган копиясе (хезмәт (эш) эшчәнлеге яңа гына башлана торган очраклардан тыш), яки гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белем турында һәм квалификация турында документларның, шулай ук, гражданинның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яки бирү турындагы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документларның нотариуста яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган копиясе;

д) гражданинда гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган авыру юклыгы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган  001-ГС/у исәп формасы);

е) 2004 елның 27 июлендәге №79-ФЗ "Россия Федерациясендә дәүләт хезмәте турында" Федераль закон белән, башка федераль законнар белән, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган башка документлар.

3.5. Министрлыкның конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре министр исеменә гариза бирә.

3.6. Бүтән төр дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы  № 667-р әмере белән расланган формадагы анкетаны үз кулы белән тутырып, имзалап  һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәте вазыйфасы били торган дәүләт органының кадрлар хезмәтендә раслатып,  фотографиясен беркетеп (4 х 6 см, почмаксыз) тапшыра.

3.7. Гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) ризалыгы белән аның дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне белә алу хокукын рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә, әгәр гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәгъвалый торган

гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи йөкләмәләрне башкару андый мәгълүматлар файдалану белән бәйле булса.

Гражданин тарафыннан министр исеменә күрсәтелгән мәгълүматлар тикшерелергә тиеш.

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеге аның Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә карый торган вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуы очрагында гына тикшерелә.

3.8. Кандидатлар тарафыннан конкурста катнашу өчен документлар, аларны кабул итү турында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында игълан урнаштырылганнан соң, 21 көн эчендә Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә тапшырыла.

3.9. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен сәбәпсез бозып тапшыру гражданиннан аларны кабул итүне кире кагу өчен нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен уңай сәбәпләр аркасында бозып тапшыру очрагында министр аларны кабул итү срогын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымнарына нигезләнгән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары файдаланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфаларына куела торган квалифкация таләпләре нигезендә эшләнде

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның группасына һәм категориясенә бәйле рәвештә, конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм сайланган бәяләү алымнары үзгәрергә мөмкин.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критеийларының якынча исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәгә 4нче Кушымтада бирелә.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар башкарган конкурс биремнәре һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре буенча ясала.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге оештыра:

конкурс үткәрү турында мәгълүмат әзерләү һәм Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру, ул үз эченә ала: вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасының (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасының) атамасы, бу вазыйфаны биләүгә дәгъва итүчегә куела торган таләпләр, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итүнең сроклары, конкурсны үткәрүнең ниятләнгән датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, бүтән

мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм конкурс турында мәгълүмат шулай ук вакытлы матбугат басмаларында да бастырылырга мөмкин;

гражданин (гражданлык хезмәткәре) тапшырган документларны тикшерү;

гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) квалификацион таләпләргә (һөнәри белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (бүтән төрләрдәге дәүләт хезмәте) стажы яки белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле һөнәри белем һәм күнекмәләре.

Конкурсның беренче этабы документлар кабул итү турында игълан урнаштырган көннән башлана һәм 21 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта төгәлләнә.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә киртә булырлык хәлләр ачыкланган очракта, аңа конкурста катнашуын кире кагу сәбәпләре турында министр тарафыннан язма рәвештә хәбәр җибәрелә.

4.4.3. Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва итүче, конкурска кертелмәгән очракта, бу карар буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирә ала.

4.4.4. Конкурсның беренче этабы төгәлләнү шарты булып Министрлыкта бер вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган икедән ким булмаган кандидат булу тора, бу кандидатларны моннан алга таба сайлауны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаган яки вазыйфага квалификация таләпләрен канәгатьләндерә торган бер генә кандидат булган очракта, конкурс булмаган дип танала. Бу очракта бердәнбер кандидат, кандидатларның таләп ителгән саны булмау сәбәпле, конкурс комиссиясе карары буенча конкурс булмады дип танылганлыгы турында язмача хәбәр ала.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы нәтиҗәсе булып билгеләнгән таләпләргә иң зур дәрәҗәдә туры килә торган һәм конкурста алга таба катнашырга тәкъдим ителә торган кандидатлар исемлеген төзү турында конкурс комиссиясенең карары тора, ул конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

4.4.6. Конкурсның беренче этабы төгәлләнгәннән соң, министр тарафыннан конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул ителгәч, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабын үткәрә.

Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башлануга кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча, конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гражданнарга (гражданлык хезмәткәрләренә) аны үткәрүнең датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәрләр җибәрә.

4.4.7. Конкурсның икенче этабында гамәлгә ашырыла:

а) конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

б) министр тарафыннан конкурс җиңүчесен Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләү (кадрлар резервына кертү) турында карар кабул итү.

4.4.8. Конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе кандидатларны алар тапшырган белем турында, гражданлык яки бүтән төр дәүләт хезмәтен узу турында, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында документлары нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган алымнары, шул исәптән кандидатлар дәгъвалый торган вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасының (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасының) вазыйфаи йөкләмәләрен башкару белән бәйле сораулар буенча тест һәм индивидуаль әңгәмә файдаланган конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

4.4.9. Кандидатларга Министрлыкта конкрет вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасына) тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 январендагы 1нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарга тест методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.10. Тест узган кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Индивидуаль әңгәмә кандидатларның конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелә торган аларның алдагы һөнәри хезмәт эшчәнлеге белән бәйле сорауларга җавапларыннан гыйбарәт, аның барышында конкурс комиссиясе гражданлык хезмәте вазыйфасына квалификация таләпләреннән чыгып һәм бу вазыйфа буенча вазыйфалар регламентының башка нигезләмәләреннән, шулай ук бу Нигезләмә белән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары белән билгеләнгән башка нигезләрдән чыгып, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау этабы нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә керткән карары тора.

4.6. Конкурс йомгакларын ясау өчен һәм Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карар чыгару өчен нигез булып конкурс комиссиясе әгъзаларының кандидатлар алган тавыш саны, кандидатлар дәгъва итә торган вазыйфа булган структур бүлекчә җитәкчесенең (Министрлык җитәкчелегенең) фикере тора.

Иң күп “өчен” дигән тавыш алган кандидат конкурс җиңүчесе булып танылa.

4.7. Конкурс үткәрү барышында вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) буенча барлык зарури таләпләргә җавап бирә торган кандидат күренмәсә, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары уздыру турында карар кабул итәргә яисә яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс җиңүчесен вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләү турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган

кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидатның ризалыгы белән, аны вакантлы гражданлык хезмәте булган группаның гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданинны) – конкурс җиңүчесен кадрлар резервына кертү Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә, Министрлык боерыгы копиясе гражданлык хезмәткәренең шәхси делосына беркетелә.

4.9. Вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирә ала.

4.10. Конкурста катнашучыларга конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр ул тәмамланганан соң 7 көн эчендә язма формада җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шулай ук күрсәтелгән срокта Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

4.11. Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс төгәлләнгәннән соң өч ел дәвамында аларның язмача гаризалары нигезендә кире кайтарылырга мөмкин. Бу срок беткәнче, документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юк ителә.

4.12. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнарны түләү (конкурсны уздыру урынына бару һәм кире кайту, вакытлыча торак өчен түләү, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз хисабына башкарыла.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгында Татарстан Республикасы
вакантлы дәүләт гражданлык
хезмәте вазыйфасын биләү
(кадрлар резервына кертү) өчен
конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә
**Кушымта №1**

Татарстан Республикасы экология
һәм табигый байлыклар министрына
_________________________________
(инициаллар, фамилия)

**Хезмәт хаты**

Сезнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итүегезне сорыйм

_________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)
_________________________________________________________________
(бүлек атамасы)

Күрсәтелгән вакантлы вазыйфаны биләүгә (күрсәтелгән вазыйфа буенча кадрлар резервына кертүгә) дәгъва итүчегә түбәндәге таләпләр куела:
белем буенча - _____________________________________________
дәүләт хезмәте стажы һәм эш тәҗрибәсе буенча - ___________________
күнекмәләре һәм сәләте буенча - _______________________________________
____________________________________________________________

Структур бүлекчә җитәкчесе

_______________ ________________________________
(дата) (имза, имзаны ачыклау)

Килешенде:
Министр урынбасары

_______________ ________________________________
(дата) (имза, имзаны ачыклау)

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгында Татарстан Республикасы
вакантлы дәүләт гражданлык
хезмәте вазыйфасын биләү
(кадрлар резервына кертү) өчен
конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә
**Кушымта №2**

Татарстан Республикасы экология
һәм табигый байлыклар министрына
______________________________
(инициаллар, фамилия)

______________________________
(фамилия, исеме, атасының исеме)
белеме __________________________,
______________________________,
(төре, уку йорты, тәмамлаган елы)

тору урыны адресы: ______________
______________________________,
тел. ____________________________,
(эш, йорт, мобиль)
e-mail ____________________________

**гариза**

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашырга рөхсәт бирүегезне үтенәм.
______________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)
______________________________________________________________
(структур бүлекчә атамасы)

2004 елның 27 июлендәге №79-ФЗ “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” Федераль закон белән, 2003 елның 16 январендагы № 3-ЗРТ “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” Татарстан республикасы Законы белән, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге №112 “Россия Федерациясендә вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс турында” Указы белән, Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында бүтән норматив хокукый актлар белән, Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурс үткәрү турында Нигезләмә белән, шул исәптән күрсәтелгән вазыйфага куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

Дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган мәгълүматларны белә алуны рәсмиләштерү процедурасын үткәрүгә риза.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail белән яки күрсәтелгән мобиль телефон номерына СМС-хәбәр җибәрү юлы белән хәбәрләмә алуга риза.

Гаризага беркетәм: (кушып бирелә торган документларны исемләп чыгарга)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ________________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны ачыклау) |

Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын биләү
(кадрлар резервына кертү) өчен
конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә
**Кушымта №3**

**Татарстан Республикасы**
**Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларга**
**таләпләр**

## 1. Гомуми таләпләр

1.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (алдга таба – гражданлык хезмәте) конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясенең 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телләрен белә торган, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфасын) биләү өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган гражданнары ия.

Гражданлык хезмәткәре Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста, ул үткәрелгәнче нинди вазыйфа биләгәнлегенә бәйсез рәвештә, гомуми нигезләрдә катнашырга хокуклы.

1.2. Гражданинга гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашу Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына квалификацион таләпләргә туры килмәве сәбәпле, шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны узуга Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары белән билгеләнгән чикләүләр белән бәйле рәвештә рөхсәт ителми.

## 2. Квалификацион таләпләр

2.1. Гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражанлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, вазыйфаи йөкләмәләрне башкару өчен зарури булган белем һәм сәләтләргә, шулай ук министрның тиешле карары булган очракта – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.

2.2. Гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре гражданлык хезмәте вазыйфаларынң категорияләре һәм группаларына, гражданлык хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төренә туры китереп билгеләнә.

2.3. Һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре:

“җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)”, “белгечләр” категорияләре буенча югары һәм төп группа гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, специалитет, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белем булу мәҗбүри;

“җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләре буенча әйдәп баручы группа гражданлык хезмәте вазыйфаларын, “белгечләр” категориясе буенча әйдәп баручы һәм өлкән группа гражданлык хезмәте вазыйфаларын, шулай ук “тәэмин итүче белгечләр” төп һәм әйдәп баручы группа гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен югары белем булу мәҗбүри;

өлкән һәм кече группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының “тәэмин итүче белгечләр” категориясе вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем булу мәҗбүри.

2.4. Гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, гражданлык хезмәткәрләре өчен зарури булган әзерлек юнәлешенә калификация таләпләре:

югары группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясе гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – өч елдан ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча җиде елдан ким булмаган эш стажы;

югары группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының “белгечләр” категориясе гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – өч елдан ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча биш елдан ким булмаган эш стажы;

төп группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының барлык категория гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – ике елдан ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча өч елдан ким булмаган эш стажы;

әйдәп баручы группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының барлык категория гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – бер елдан ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан ким булмаган эш стажы.

Өлкән һәм кече группа гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре куелмый.

Гражданлык хезмәте стажын билгеләгәндә, тиешле вазыйфа группаларының федераль дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларында, хәрби вазыйфаларда һәм бүтән төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфа группаларының муниципаль хезмәт вазыйфаларында, һәм федераль законнар нигезендә бүтән төр вазыйфаларда эш стажы да санала.

2.5. Эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган фәнни дәрәҗәгә ия булган затлар тарафыннан төп һәм әйдәп баручы группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясе гражданлык хезмәте вазыйфалары һәм төп һәм әйдәп баручы группа гражданлык хезмәте вазыйфаларының “белгечләр” категориясе гражданлык хезмәте вазыйфалары биләнгәндә, гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, дәүләт органы

җитәкчесе карары буенча, бу Таләпләрнең 2.4 пунктында билгеләнгән квалификация таләпләре исәпләнмәскә мөмкин.

2.6. Белгеч яки магистрның кызыл дипломына ия булган затлар өчен, диплом алганнан соң өч ел дәвамында, гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларын биләү өчен квалификацион таләпләр билгеләнә – бер елдан ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча стаж.

2.7. Вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү өчен зарур булган белем һәм сәләтләргә квалификация таләпләре гражданлык хезмәткәренең професссиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төре белән бәйле рәвештә аның вазыйфа регламенты белән билгеләнә. Гражданлык хезмәткәренең вазыйфа регламенты белән шулай ук белгечлеккә, гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәкле әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре дә игътибарга алынырга мөмкин.

Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын биләү
(кадрлар резервына кертү) өчен
конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә
**Кушымта №4**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәтенең  вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурста катнашучыларны бәяләү
**Критерийлары**

**1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте культурасына ярашлылык**

1.1. Һөнәри мотивация

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендә үз-үзеңне һөнәри реализацияләүгә омтылу, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәт үсешенә ориентлашу.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законлылыкны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен үтәү принципларын саклау.

1.3. Һөнәри позициянең активлыгы

Куелган бурычларны үтәгәндә, инициатива күрсәтергә омтылу; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәне алу өчен зур көч куярга әзерлек, физик һәм эмоциональ йөкләнешләр шартларында нәтиҗәле эш итү сәләте (стрессларга каршы торучанлык).

1.4. Үзлегеннән үсешкә әзерлек

Үз белемнәрен, сәләтен һәм күнекмәләрен камилләштерүгә, дөньяга карашларын киңәйтүгә, эргәдәш профессия өлкәләрендә белем һәм тәҗрибә алуга даими омтылыш.

**2. Гражданлык хезмәткәренең һөнәри компетентлыгы**

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белемнең дәрәҗәсе, профиле һәм сыйфаты

2.2. Һөнәри тәҗрибә

Туры килә торган һөнәри өлкәдә эшчәнлекнең дәвамлылыгы һәм үзенчәлекләре;

һөнәри эшчәнлектә конкрет нәтиҗәләргә ирешү;

карьера үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәр, сәләт һәм күнекмәләр

Тиешле өлкәдәге профессиональ белемнәрнең функциональ йөкләмәләрне нәтиҗәле башкарырга мөмкинлек бирә торган дәрәҗәсе;

Россия Федерациясенең һөнәри эшчәнлекне регламентлаштыра торган законнарын белү;

заманча һөнәри технологияләрне белү.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләр

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген күтәрә торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютер белән эш итә белү, гомуми грамоталылык, чит телләр белү һ.б).

**3. Гражданлык хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары**

3.1. Аналитик сәләтләр

Фикерләүнең мәгълүматны анализларга һәм структуралаштырырга мөмкинлек бирә торган системалылыгы һәм сыгылмалылыгы дәрәҗәсе;

яңа, стандарт булмаган чишелешләр табу сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникация күнекмәләре

Эшлекле аралашу этикасын үтәү;

үз фикерен дәлилләп яклый белү һәм оппонентларны ышандыра белү сәләте;

эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булу.

3.3. Җаваплылык

Карарлар кабул итүдә нигезлелек һәм мөстәкыйльлек;

нәтиҗәләргә ирешүдә үзенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзерлек.

3.4. Оештыру сәләте

Үз эшчәнлеген һәм кул астында эшләүчеләрнең эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, функцияләрне, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү исәбенә нәтиҗәләргә ирешә белү.